| | |
|---|---|
| **ГЛАВА КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь 2024 ел Колаңгы станциясе № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Колаңгы авыл җирлеге Бәли
торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 27 нояберендә 10 сәг 00 минутка Бәли авылы , Кызыл урамы, 63А йорт адресы буенча , үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 27 нояберендә 14 сәг 00 минутка Бәли авылы , Кызыл урамы, 18 йорт адресы буенча , үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын икенче этабын билгеләргә

3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү ;
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар төзү, ремонтлау;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Интернет - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең http://kulangin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колангы авыл җирлеге башлыгы Ф.Т.Нигматзянов